**Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» ноябрь, 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы карары нигезендә Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

**1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чишмәгә төшү юлын ремонтлау).**
**2) урам яктырту эшләрен башкару (урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу).**

2. Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, контракт төзегәннәрне, доброволецларны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков